СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Решение** **Карар**

№ 8-6 от « 14 » апреля 2026 г.

«2026 елга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы турында»

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2026 елга «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фараз планын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениесенә 2026 елга «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2025 елның 26 декабрендәге «2026 елга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы турында» 3-4 номерлы карарын үз көчен югалтты дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениесенә йөкләргә.

Мамадыш муниципаль район,
Башлыгы В.И.Никитин

000019

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Советының
14.04.2026 ел , № 8-6 карары
белән расланды

## 2026 елга «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы)

### 1 бүлек. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру өлкәсендә сәясәтне гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре һәм бурычлары

2025 елга «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Көндәшлекне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыру мәсьәләләрен җайга салучы башка норматив-хокукый актлар, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 31 октябрендә 10-35 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыру турында Нигезләмә нигезендә эшләнгән.

Мамадыш муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыруның төп бурычы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнары функцияләрен (вәкаләтләрен) һәм бурычларын тәэмин итү өчен файдаланылмый торган һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнмәгән муниципаль милекне хосусыйлаштыру хисабына муниципаль милек структурасын оптимальләштерү.

Муниципаль милекне хосусыйлаштыру программасы түбәндәге бурычларны хәл итүгә юнәлдереләчәк:

- тулаем алганда, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы икътисады һәм аерым хуҗалык итүче субъектларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру;
- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы бюджетына муниципаль милекне хосусыйлаштырудан планлаштырылган барлык керемнәрнең дә үз вакытында һәм тулаем керүе;
- муниципаль милекне хосусыйлаштырудан кергән акчалар хисабына җирле бюджетны тулыландыру;
- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы икътисадын һәм аның инфраструктурасын үстерү өчен инвестиция чараларын җәлеп итү;

2026 елга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) гамәлдә булу срогы дәвамында аңа Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы карары нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелә ала.

Ел дәвамында муниципаль милектә булган хосусыйлаштырылмаган муниципаль милек объектлары киләсе елга фараз планына кертелә.

2 бүлек. 2026 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган муниципаль милек объекты исемлеге һәм характеристикасы

1.Муниципаль милек:

| № п/п | исеме | Урнашу адресы | Хосусыйлаштыру ысулы | Гамәлгә ашыруның күздә тотылган вакыты | Кем балансында тора |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Chevrolet Niva, 212300-55, караңгы- соры төстә VINX9L212300G0609706 г.н Х784ср 116 | ТР, Мамадыш муниципаль районы, Мамадыш ш. М.Җәлил ур, 23/33 й | ачык аукцион | 1 квартал 2026 | ТР Мамадыш муниципаль районы Советы |
| 2 | CHEVROLET NIVA 212300-55 VIN X9L212300G0579304 госномер У317 ХН | ТР, Мамадыш муниципаль районы, Мамадыш ш. М.Җәлил ур, 23/33 й | ачык аукцион | 2 квартал 2026 | ТР Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 3 | 16:26:090103:668 кадастр номерлы мунча бинасы 16:26:090103:81 кадастр номерлы җир кишәрлеге | ТР, Мамадыш районы Мамадыш совхозы поселогы Мәктәп ур.7 йорт | ачык аукцион | 2 квартал 2026 | ТР Мамадыш муниципаль районы |
| 4 | 16:26:000000:3541 кадастр номерлы мунча бинасы 16:26:340236:231 кадастр номерлы җир кишәрлеге | ТР, Мамадыш районы, Мамадыш ш., Нократ Яр буе урамы, 116 а | ачык аукцион | 2 квартал 2026 | ТР Мамадыш муниципаль районы |
| 5 | 16:26:340128:499 кадастр номерлы торак булмаган бина | ТР, Мамадыш районы, Мамадыш ш. Совет ур.,11/6 №21 бина | ачык аукцион | 2 квартал 2026 | ТР Мамадыш муниципаль районы |
| 6 | УАЗ-315194, Госномер, VIN ХТТ31519470540509 Г.н. Р869ОС 716 | ТР, Мамадыш муниципаль районы, Мамадыш ш. М.Җәлил ур. 23/33 | ачык аукцион | 2 квартал 2026 | ТР Мамадыш муниципаль районы |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 7 | Lada Niva VIN-X9L212300L0716174 Гос. номер н977ку 716 | ТР, Мамадыш муниципаль районы, Кече Сон ав, Гагарин ур., 12а | ачык аукцион | 2 квартал 2026 | ТР Никифорово авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 8 | HYNDAI AERO EXPRESS VIN-KMJRL18C5C003099 гос.номер В277ХВ 116 | ТР, Мамадыш муниципаль районы Кече Сон ав, Гагарин ур., 12а | ачык аукцион | 2 квартал 2026 | ТР Мамадыш муниципаль районы Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге МКУ |
| 9 | CHEVROLE NIVA 212300-55 VIN-X9L212300E0497368 госномер С729 УМ 116 | ТР, Мамадыш муниципаль районы, Кече Сон ав, Гагарин ур., 12а | ачык аукцион | 2 квартал 2026 | ТР Мамадыш муниципаль районының хоккей һәм физик культура буенча балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе МБУ |
| 10 | CHEVROLE NIVA 212300-55 госномер В546ХМ X9L212300L0699317 | ТР, Мамадыш муниципаль районы, Мамадыш ш. М.Җәлил ур. 23/33 | ачык аукцион | 3 квартал 2026 | ТР Югары Ушма авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 11 | 16:26:030201:287 кадастр номерлы торак булмаган бина 16:26:030201:272 кадастр номерлы җир кишәрлеге белән | ТР, Мамадыш муниципаль районы, с.Малая Сунь, ул.Гагарина д.12а | ачык аукцион | 3 квартал 2026 | ТР Сон авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 12 | LADA NIVA VIN XTA212300R0864736 Госномер С141ЕТ 716RUS | ТР, Мамадыш муниципаль районы, с.Малая Сунь, ул.Гагарина д.12а | ачык аукцион | 3 квартал 2026 | ТР ММР Яке авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 13 | Peugeot Partner VIN VF37JNFRCCJ743351 гос.номер О917ХУ 116 | ТР, Мамадыш муниципаль районы, Мамадыш ш. М.Җәлил ур. 23/33 | ачык аукцион | 3 квартал 2026 | ТР ММР Мәгариф бүлеге МКУ |
| 14 | Шевроле НИВА212300-55 VIN X9L212300G0602369 гос.номер | ТР, Мамадыш муниципаль районы, Мамадыш ш. М.Җәлил ур. 23/33 | ачык аукцион | 3 квартал 2026 | ТР Мамадыш муниципаль районы Советы |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Х219ВН 116 | | | | |
| 15 | ФИАТ АЛБЕА VIN XU31780009Z12877 9 гос номер в351ев 116 | ТР, Мамадыш муниципаль районы, Мамадыш ш. М.Җәлил ур. 23/33 | ачык аукцион | 3 квартал 2026 | ТР Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 16 | Шевроле НИВА212300-55 VIN X9L212300L071589 8 гос.номер М887 МЕ 116 | ТР, Мамадыш муниципаль районы, Мамадыш ш. М.Җәлил ур. 23/33 | ачык аукцион | 3 квартал 2026 | ТР Мамадыш муниципаль районы Көмеш Күл авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 17 | Шевроле НИВА212300-55 VIN X9L212300L071920 9 гос.номер Н462 ОМ 116 | ТР, Мамадыш муниципаль районы, Мамадыш ш. М.Җәлил ур. 23/33 | ачык аукцион | 3 квартал 2026 | ТР Мамадыш муниципаль районы Көмеш Күл авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 18 | HYUNDAI NF SONATA VIN-KMHEU41AP9A66 7014 гос.номер М776 ТТ 116 | ТР, Мамадыш муниципаль районы, Мамадыш ш. М.Җәлил ур. 23/33 | ачык аукцион | 3 квартал 2026 | Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «ДДЮ " өстәмә белем бирү МБМУ |
| 19 | ПАЗ 32053-70, VIN-X1M3205BXG0002 596 гос.номер Х474 ВН 116 | ТР, Мамадыш муниципаль районы, Мамадыш ш Совет ур., 2А | ачык аукцион | 3 квартал 2026 | ТР Мамадыш муниципаль районы Җөри авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 20 | ПАЗ 32053-70, VIN-X1M3205BXG0002 598 гос.номер Х543 ВН 116 | ТР, Мамадыш муниципаль районы, Мамадыш ш Совет ур., 2А | ачык аукцион | 3 квартал 2026 | Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының "Олыяз лицее" МБМУ |

Хосусыйлаштыру программасын гамәлгә ашыру sale.zakazrf.ru электрон сәүдә мәйданчыгында аукцион уздыру юлы белән, шул исәптән хосусыйлаштыру ысулларын һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның бәяләү эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә билгеләнгән башлангыч бәясен үз эченә алып, гамәлгә ашырылачак.

Әлеге программада каралган хосусыйлаштыру шартлары турында Карар кабул итү муниципаль милекне хосусыйлаштыру максатларын һәм бурычларын тормышка ашырырга мөмкинлек бирәчәк.